**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 32ейорт, Чирмешәнавылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email:cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

18 июль 2019 ел №235

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2012 елның 11 декабрендәге
135 номерлы «Чирмешән муниципаль
районының территориаль планлаштыру
схемасын раслау турында » карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 пунктының 15 пунктчасы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2012 елның 11 декабрендәге 135 номерлы «Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында»карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасында, муниципаль районны электр белән тәэмин итү схемасын эшләү юлы белән, «Челтәр компаниясе»ААҖ энергетика объектларын чагылдырырга.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына кушымталар нигезендә үзгәрешләр кертү буенча чаралар планын һәм үтәлү вакытын расларга.

3. Муниципаль районның электр белән тәэмин итү схемасын эшләү буенча эшләрне финанслау «Челтәр компаниясе»ААҖ хисабына башкарыла.

4. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» район газетасының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзелеш, җир төзелеше, авыл хуҗалыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Башлык, муниципаль район

Совет рәисе башлыгы Ф. М. Дәүләтшин